| | | |
|---|---|---|
| УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ |

ПРИКАЗ

«16» 06 2015 ел

БОЕРЫК

№ 01-05/94-пр

**Татарстан Республикасының Дәүләт техник күзәтчелек итү идарәсендә дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

«Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ( кертемнәр ) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, аларда акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм ( яисә ) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктындагы «и» пунктчасы, Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы тору турында кайбер мәсьәләләре буенча» 2015 елның 8 мартындагы 120 номерлы Указының 2 пункты нигезендә һәм Татарстан Республикасыны Президентының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләренә, алар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 8 июнендәге 542 номерлы Указының 2 пунктын үтәү йөзеннән, боерам:

1. Татарстан Республикасының Дәүләт техник күзәтчелек итү идарәсендә дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасының Дәүләт техник күзәтчелек итү идарәсенең оештыру-хокук эшләре бүлегенә (Л.М.Әблиева):

кабул ителгән көненнән башлап өч көн эчендә, исемлеккә кертелгән Татарстан Республикасының Дәүләт техник күзәтчелек итү идарәсенең дәүләт граждан хезмәткәрләрен, әлеге боерык белән имза салып таныштырырга;

әлеге боерык белән расланган исемлекне, расланганнан соң 3 көн вакыт эчендә,ә алга таба, үзгәрешләр кертелгән очракта, үзгәрешләр кертелгәннән соң бер атна вакыт эчендә анықланган исемлекләрне Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә тапшырырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык Р.Р.Зиатдинов

Татарстан Республикасының
Дәүләт техник күзәтчелек итү идарәсе
16.06.2015 01-05/94-пр номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының Дәүләт техник күзәтчелек итү идарәсендә дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

| Тәртип номеры | Вазыйфаның исеме | Вазыйфалар саны | Вазыйфалар төркеме |
|---|---|---|---|
| 1 | Идарә башлыгы-Татарстан Республикасының Дәүләт техник күзәтчелек итү идарәсе баш дәүләт инженер-инспекторы | 1 | югары |